Хокукый акт проекты буенча гавами тыңлаулар башлану турында
ХӘБӘР ИТҮ

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының «Олы Кайбыч авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар башлануы турында хәбәр итәбез.

Проектка мәгълүмати материаллар исемлеге:

1. Шәһәр төзелеше регламентлары;
2. Шәһәр төзелеше зоналаштыру картасы;
3. Территорияләрдән файдаланунын махсус шартлары булган зона картасы;
4. Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрен куллану һәм күрсәтелгән кагыйдәләргә үзгәрешләр кертү тәртибе.

Проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрү тәртибе һәм сроклары:

1. Гавами тыңлауларга чыгарылган мәсьәләнең асылы буенча чыгышлар.
2. Гавами тыңлауларда катнашучыларның сорауларын һәм тәкъдимнәрен карау.

Гавами тыңлауларда катнашучылар чыгыш ясаучыларга барлык чыгышлар тәмамланганнан соң сораулар бирергә хокуклы. Сораулар һәм тәкъдимнәр язма рәвештә бирелә. Гавами тыңлаулар үткәрү срогы: 2025 елның 28 апреленнән 2025 елның 4 августына кадәр.

Гавами тыңлауларда катнашучылар даирәсе: Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты, җир кишәрлеге урнашкан территориаль зона чикләрендә даими яшәүче гражданнар, шушы территориаль зона чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләренең һәм (яисә) аларда урнашкан капиталь төзелеш объектларының хокук ияләре, җир кишәрлеге чикләрендә даими яшәүче гражданнар, шундый җир кишәрлекләренең яисә аларда урнашкан капиталь төзелеш объектларының хокук ияләре, капиталь төзелеш объектының бер өлеше булган биналарның хокук ияләре.

Ачык тыңлауларда каралырга тиешле проект экспозициясен (экспозицияләрен) ачу урыны һәм датасы: Кайбыч районы, Олы Кайбыч ав., Кояшлы бульвар, 7 й., 2 нче кат, 209 нчы кабинет адресы буенча урнашкан Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге.

Экспозициягә (экспозицияләргә) бару мөмкинлеге булган көннәр һәм сәгатьләр турында мәгълүмат: 2025 елның 28 июленнән 2025 елның 4 августына кадәр эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә хәтле.

Проектка кагылышлы тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне гавами тыңлауларда катнашучылар тарафыннан кертү тәртибе, сроклары һәм рәвеше: Кайбыч районы, Олы Кайбыч ав., Кояшлы бульвар, 7 й., 2 кат, 209 нчы кабинет адресы буенча урнашкан Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлегендә 2025 елның 28 июленнән 2025 елның 4 августына кадәр язма рәвештә кабул ителә.

Гавами тыңлауларда катнашучылар җыелышын уздыру датасы, вакыты һәм урыны турында мәгълүмат 2025 елның 04 августында:

- 10.00 сәгатьтә Кайбыч районы, Олы Кайбыч ав., Кояшлы бульвар, 7 й., 2 кат, 209 нчы кабинет адресы буенча урнашкан Иҗтимагый үзәкнең актлар залында;
- 11.00 сәгатьтә Кайбыч районы, Иске Чәчкаб ав., , Клуб ур., 4 й. адресы буенча урнашкан Иске Чәчкаб авылы клубы бинасында;

- 13.00 сәгатьтә Кайбыч районы, Афанасьевка ав., а ур., . 11й. адресы буенча урнашкан Афанасьевка авыл клубы бинасында;
- 14.00 сәгатьтә Кайбыч районы, Симәки ав., Үзәк ур., 1а й. адресы буенча урнашкан Симәки фельдшер -акушерлык пункты янында.

Гавами тыңлауларда каралырга тиешле проект һәм аңа карата мәгълүмати материаллар урнаштырылган рәсми сайт турында мәгълүмат: Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтының «Башкарма комитет карарлары» бүлегендә (http://kaybici.tatarstan.ru).

Әлеге хәбәрне Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында «Сайтка керүчеләр өчен файдалы мәгълүмат» бүлегендә (http://kaybici.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru/) һәм Кайбыч районы, Олы Кайбыч ав., Кояшлы бульвар, 7 й., 2 кат, 209 нчы кабинет адресы буенча урнашкан Иҗтимагый үзәк, Кайбыч районы, Иске Чәчкаб ав., , Клуб ур., 4 й. адресы буенча урнашкан Иске Чәчкаб авылы клубы, Кайбыч районы, Афанасьевка ав., а ур., . 11й. адресы буенча урнашкан Афанасьевка авыл клубы, Кайбыч районы, Симәки ав., Үзәк ур., 1а й. адресы буенча урнашкан Симәки фельдшер -акушерлык пункты мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Башкарма комитеты Җитәкчесе А.Н. Макаров